# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О молодежной политике в Республике Татарстан» и Закон Республики Татарстан «О патриотическом воспитании граждан в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
28 марта 2025 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 19 октября 1993 года № 1983-XII «О молодежной политике в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 мая 2021 года № 35-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1993, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2021, № 36 (часть I); 2023, № 11 (часть I), № 27 (часть I); 2024, № 45 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 5 статьи 3 изложить в следующей редакции:

«5) формирование системы нравственных и смысловых ориентиров, позволяющих противостоять идеологиям экстремизма, агрессивного национализма, проявлениям ксенофобии, коррупции, дискриминации по признакам социальной, религиозной, расовой, национальной принадлежности и другим негативным социальным явлениям и деструктивным идеологиям;»;

2) пункт 2 статьи 4 после слова «Федерации» дополнить словами «, органов публичной власти федеральной территории «Сириус»;

3) статью 5 изложить в следующей редакции:

«Статья 5. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере молодежной политики**

К полномочиям органов государственной власти Республики Татарстан в сфере молодежной политики относятся:

1) реализация молодежной политики на территории Республики Татарстан, в том числе разработка и осуществление мер, мероприятий, способствующих реализации основных направлений молодежной политики;

2) нормативно-правовое регулирование в сфере молодежной политики с учетом социальных потребностей молодежи, национальных традиций, региональных, местных и этнокультурных особенностей Республики Татарстан;

3) определение органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственное управление в сфере молодежной политики в Республике Татарстан (далее – орган исполнительной власти в сфере молодежной политики);

4) разработка и реализация республиканских и межмуниципальных программ по основным направлениям молодежной политики с учетом социально-экономических, экологических, демографических, этнокультурных и других особенностей Республики Татарстан, в том числе направленных на формирование у молодежи духовно-нравственных ценностей, интереса и уважения к традициям, обычаям и культуре татарского народа и народов, проживающих на территории Республики Татарстан;

5) утверждение порядка межведомственного взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан и иных субъектов Российской Федерации при реализации молодежной политики;

6) содействие развитию инфраструктуры молодежной политики, в том числе создание и обеспечение функционирования учреждений молодежной политики, на территории Республики Татарстан;

7) организация деятельности специалистов по работе с молодежью;

8) организация и осуществление мониторинга реализации молодежной политики, в том числе мониторинга эффективности патриотического воспитания молодежи и духовно-нравственного воспитания молодежи, на территории Республики Татарстан;

9) содействие занятости молодежи, формированию ценности труда и получению практических навыков, в том числе посредством студенческих отрядов, на территории Республики Татарстан;

10) содействие реализации выдвигаемых инициатив, в том числе инициативных проектов, молодежи Республики Татарстан;

11) поддержка и развитие различных форм воспитательной работы в молодежных и детских общественных объединениях, организациях, осуществляющих образовательную деятельность;

12) создание условий для оздоровления и отдыха молодежи;

13) экологическое просвещение и вовлечение молодежи в мероприятия по защите природы, сохранению и улучшению состояния окружающей среды;

14) создание условий для психолого-педагогической помощи и социальной адаптации молодых граждан;

15) иные полномочия в сфере молодежной политики, отнесенные в соответствии с Федеральным законом, другими федеральными законами, законами Республики Татарстан к полномочиям органов государственной власти Республики Татарстан.»;

4) в статье 6:

а) в абзаце первом слова «К полномочиям» заменить словами «1. К полномочиям»;

б) дополнить пунктом $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$) содействие развитию инфраструктуры молодежной политики, в том числе создание и обеспечение функционирования муниципальных учреждений молодежной политики, на территории муниципального образования;»;

в) в пункте 4 слово «реализации» исключить;

г) дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) содействие реализации выдвигаемых инициатив, в том числе инициативных проектов, молодежи муниципального образования;»;

д) пункт 5 после слов «молодежной политики» дополнить словами «, в том числе мониторинга эффективности патриотического воспитания молодежи и духовно-нравственного воспитания молодежи,»;

е) дополнить частью 2 следующего содержания:

«2. Главы муниципальных образований вправе создавать координационные органы в сфере молодежной политики. Порядок создания координационного органа в сфере молодежной политики при главе муниципального образования определяется правовым актом главы муниципального образования.»;

5) в статье 7:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 7. **Основные направления молодежной политики в Республике Татарстан**»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. В соответствии с Федеральным законом основными направлениями молодежной политики в Республике Татарстан являются:

1) патриотическое воспитание молодежи;

2) духовно-нравственное воспитание молодежи;

3) обеспечение межнационального (межэтнического) и межконфессионального согласия в молодежной среде, профилактика и предупреждение проявлений экстремизма в деятельности молодежных общественных объединений, формирование у молодежи на основе традиционных российских духовно-нравственных ценностей неприятия идеологий терроризма, экстремизма, иных деструктивных идеологий, а также формирование устойчивости к их пропаганде;

4) обеспечение защиты прав и законных интересов молодежи;

5) поддержка молодых граждан, оказавшихся в трудной жизненной ситуации, инвалидов и лиц с ограниченными возможностями здоровья из числа молодых граждан, лиц из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, а также содействие в оказании социально-психологической помощи молодежи;

6) поддержка инициатив, в том числе инициативных проектов, молодежи;

7) содействие общественной деятельности, направленной на поддержку молодежи;

8) организация досуга, отдыха и оздоровления молодежи, вовлечение молодых граждан в социальный и внутренний туризм, в том числе путем организации и проведения походов, экспедиций, слетов, фестивалей и иных мероприятий, проводимых в условиях природной среды;

9) формирование условий для занятий физической культурой, спортом, содействие здоровому образу жизни молодежи и его популяризации в молодежной среде, поддержка проектов молодежи, направленных на решение социальных задач через развитие физической культуры и спорта;

10) предоставление социальных услуг молодежи;

11) содействие решению жилищных проблем молодежи, молодых семей;

12) поддержка молодых семей, сохранение и укрепление традиционных семейных ценностей и семейного образа жизни в молодежной среде, создание условий для обеспечения ответственного родительства среди молодежи;

13) содействие образованию молодежи, научной, научно-технической деятельности молодежи, повышению мотивации у молодых граждан к получению новых знаний, в том числе путем самообразования, поддержка молодых ученых;

14) правовое просвещение и правовое информирование молодежи;

15) организация подготовки специалистов по работе с молодежью;

16) выявление, сопровождение и поддержка молодежи, проявившей одаренность, содействие реализации прав молодых граждан на свободу литературного, художественного, научного, технического и других видов творчества;

17) развитие института наставничества;

18) обеспечение гарантий в сфере труда и занятости молодежи, содействие трудоустройству молодых граждан, в том числе посредством студенческих отрядов, профессиональному развитию молодых специалистов и молодых работников;

19) поддержка и содействие предпринимательской деятельности молодежи;

20) формирование условий для самореализации молодых граждан через их вовлечение в социально-экономическое развитие сельских территорий и повышение привлекательности сельского образа жизни;

21) поддержка деятельности молодежных общественных объединений, некоммерческих организаций, осуществляющих деятельность, направленную на реализацию молодежной политики, и органов молодежного самоуправления при органах государственной власти Республики Татарстан, органах местного самоуправления и организациях в Республике Татарстан;

22) содействие участию молодежи в добровольческой (волонтерской) деятельности;

23) формирование у молодежи экологической культуры и экологически ответственного мировоззрения;

24) содействие международному и межрегиональному сотрудничеству в сфере молодежной политики;

25) предупреждение правонарушений и антиобщественных действий молодежи;

26) поддержка деятельности по созданию и распространению в средствах массовой информации, в том числе в информационно-телекоммуникационной сети

«Интернет», произведений науки, искусства, литературы и других произведений, направленных на укрепление гражданской идентичности, патриотическое воспитание молодежи и духовно-нравственное воспитание молодежи;

27) проведение научно-аналитических исследований по вопросам молодежной политики.»;

6) часть 4 статьи 8 изложить в следующей редакции:

«4. Соответствие обращающегося за государственной поддержкой молодежного или детского общественного объединения установленным настоящим Законом требованиям определяется органом исполнительной власти в сфере молодежной политики.»;

7) в статье 12:

а) часть 1 после слов «местного самоуправления» дополнить словами «, учреждения молодежной политики»;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Информация о реализации молодежной политики включает в себя данные официального статистического учета, касающиеся реализации молодежной политики, данные мониторинга реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан, в том числе мониторинга эффективности патриотического воспитания молодежи и духовно-нравственного воспитания молодежи на территории Республики Татарстан, и иные данные, получаемые при осуществлении своих функций органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, учреждениями молодежной политики, а также иными организациями, осуществляющими деятельность в сфере молодежной политики.»;

8) в статье 13:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Мониторинг реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан представляет собой систематическую, комплексную и плановую деятельность по сбору, обобщению, анализу и оценке информации о положении молодежи, молодых семей и молодежных общественных объединений в Республике Татарстан, деятельности учреждений молодежной политики, Общероссийского общественно-государственного движения детей и молодежи «Движение первых», об участии молодежи в общественно полезной деятельности в области образования, просвещения, науки, культуры, искусства, здравоохранения, физической культуры и спорта, о занятости и безработице в молодежной среде, об обеспечении межнационального (межэтнического) и межконфессионального согласия в молодежной среде, о предотвращении формирования экстремистских молодежных общественных объединений, проявлений идеологий экстремизма, агрессивного национализма в деятельности таких объединений, о формировании у молодежи на основе традиционных российских духовно-нравственных ценностей неприятия идеологий терроризма, экстремизма, иных деструктивных идеологий, а также о формировании устойчивости к их пропаганде в целях подготовки доклада

о положении молодежи в Республике Татарстан (далее – доклад).»;

б) дополнить частью 1[1] следующего содержания:

«1[1]. Мониторинг эффективности патриотического воспитания молодежи и духовно-нравственного воспитания молодежи на территории Республики Татарстан является частью мониторинга реализации молодежной политики на территории Республики Татарстан и представляет собой деятельность по сбору, обобщению, анализу и оценке информации о деятельности органов публичной власти и иных субъектов, осуществляющих деятельность в сфере молодежной политики, по патриотическому воспитанию молодежи и духовно-нравственному воспитанию молодежи.»;

в) часть 4 после слов «местного самоуправления,» дополнить словами «учреждений молодежной политики и».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 9 декабря 2023 года № 123-ЗРТ «О патриотическом воспитании граждан в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2023, № 92 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 статьи 2 изложить в следующей редакции:

«1. Для целей настоящего Закона под патриотическим воспитанием понимается систематическая и целенаправленная деятельность органов публичной власти и иных субъектов патриотического воспитания по формированию у граждан любви и уважения к Отечеству, верности ему и чувства личной ответственности за судьбу Отечества перед нынешним и будущими поколениями, готовности к выполнению гражданского долга и конституционной обязанности по защите Отечества, а также по защите исторической правды и сохранению исторической памяти, формированию и укреплению у граждан общероссийской гражданской идентичности (в том числе на основе особенностей Республики Татарстан и народных традиций соответствующей территории), уважения к отечественной истории и гордости за достижения Отечества и ее граждан, развитию общественно значимой созидательной активности граждан.»;

2) пункт 2 части 3 статьи 3 после слов «Республики Татарстан» дополнить словами «, местным традициям»;

3) в статье 5:

а) в пункте 5 слова «в сфере молодежной политики,» исключить;

б) дополнить пунктом 5[1] следующего содержания:

«5[1]) субъекты, осуществляющие деятельность в сфере молодежной политики;»;

4) в статье 6:

а) часть 3 дополнить пунктом 3[1] следующего содержания:

«$3^{1}$) утверждение регионального комплекса мер по патриотическому воспитанию молодежи и духовно-нравственному воспитанию молодежи с учетом положений, предусмотренных комплексом мер по патриотическому воспитанию молодежи и духовно-нравственному воспитанию молодежи в Российской Федерации, социальных потребностей молодежи, национальных традиций, региональных, местных и этнокультурных особенностей Республики Татарстан и организация его реализации;»;

б) в части 5:

дополнить пунктами $4^{1}$ и $4^{2}$ следующего содержания:

«$4^{1}$) содействие деятельности центров патриотического воспитания, военно-патриотических объединений (клубов), историко-краеведческих и поисковых организаций, общественно-государственных и общественных объединений, уполномоченных на проведение поисковой работы, осуществляемой в целях выявления неизвестных воинских захоронений и непогребенных останков, установления имен погибших и пропавших без вести при защите Отечества и увековечения их памяти;

$4^{2}$) содействие деятельности некоммерческих организаций и общественных объединений, осуществляющих деятельность в сфере патриотического воспитания молодежи и духовно-нравственного воспитания молодежи;»;

дополнить пунктом $5^{1}$ следующего содержания:

«$5^{1}$) осуществление мониторинга эффективности патриотического воспитания молодежи и духовно-нравственного воспитания молодежи на территории Республики Татарстан;».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
10 апреля 2025 года
№ 19-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) экстремизм, агрессив милләтчелек идеологияләренә, ксенофобия, коррупция, социаль, дини, раса, милли билгеләр буенча дискриминация чагылышларына һәм башка тискәре социаль күренешләргә һәм деструктив идеологияләргә каршы торырга мөмкинлек бирә торган әхлакый һәм мәгънәви ориентирлар системасын булдыру;»;

2) 4 статьяның 2 пунктында «Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарының» сүзләреннән соң «, «Сириус» федераль территориясе гавами хакимият органнарының» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

Яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, шул исәптән яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыруга ярдәм итә торган гамәлләрне, чараларны эшләү һәм башкару;

2) яшьләрнең социаль ихтыяҗларын, Татарстан Республикасы милли традицияләрен, региональ, җирле һәм этномәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу;

3) Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү (алга таба – яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы);

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте өлкәсендә төп юнәлешләр буенча, шул исәптән яшьләрдә рухи-әхлакый кыйммәтләр, татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның традицияләренә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә кызыксыну һәм хөрмәт булдыруга юнәлдерелгән, республика программаларын һәм муниципальара программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

5) яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен билгеләү;

6) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерүгә булышлык күрсәтү, шул исәптән яшьләр сәясәте учреждениеләрен булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;

7) яшьләр белән эшләүче белгечләрнең эшчәнлеген оештыру;

8) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны, шул исәптән яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны, оештыру һәм үткәрү;

9) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрне эш белән тәэмин итүгә, хезмәт кыйммәтләре формалашуга һәм гамәли күнекмәләр алуга булышлык күрсәтү, шул исәптән студентлар отрядлары ярдәмендә;

10) Татарстан Республикасы яшьләре тарафыннан тәкъдим ителә торган инициативаларны, шул исәптән инициатив проектларны, гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

11) яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрендә, мәгариф эшчәнлеген башкара торган оешмаларда тәрбия эшенең төрле рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү;

12) яшьләрне сәламәтләндерү һәм аларның ялы өчен шартлар тудыру;

13) яшьләрне экологик агарту һәм табигатьне яклау, әйләнә-тирә мохит торышын саклау һәм яхшырту чараларына җәлеп итү;

14) яшь гражданнарга психологик-педагогик ярдәм һәм социаль җайлашу өчен шартлар тудыру;

15) Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләр.»;

4) 6 статьяда:

а) беренче абзацта «Яшьләр сәясәте» сүзләрен «1. Яшьләр сәясәте» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2[1] пункт өстәргә:

«2[1]) муниципаль берәмлек территориясендә яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерүгә булышлык күрсәтү, шул исәптән муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләрен булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;»;

в) 4 пунктта «сәясәтен гамәлгә ашыруның» сүзләрен «сәясәтенең» сүзенә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 4[1] пункт өстәргә:

«4[1]) муниципаль берәмлек яшьләре тарафыннан тәкъдим ителә торган инициативаларны, шул исәптән инициатив проектларны, гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;»;

д) 5 пунктта «мониторинглауны» сүзеннән соң «, шул исәптән яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны,» сүзләрен өстәргә;

е) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлекләр башлыклары яшьләр сәясәте өлкәсендә координация органнары булдырырга хокуклы. Муниципаль берәмлек башлыгы каршындагы яшьләр сәясәте өлкәсендә координация органын булдыру тәртибе муниципаль берәмлек башлыгының хокукый акты белән билгеләнә.»;

5) 7 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре**»;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) яшьләргә патриотик тәрбия бирү;

2) яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү;

3) яшьләр мохитендә милләтара (этникара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, яшьләр иҗтимагый оешмалары эшчәнлегендә экстремизм чагылышларын профилактикалау һәм кисәтү, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә яшьләрдә терроризм, экстремизм идеологияләрен, башка деструктив идеологияләрне кабул итә алмауны тәрбияләү, шулай ук аларны пропагандалауга каршы торучанлык булдыру;

4) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү;

5) авыр тормыш хәлендә калган яшь гражданнарга, яшь гражданнар арасыннан булган инвалидларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга ярдәм итү, шулай ук яшьләргә социаль-психологик ярдәм итүгә булышлык күрсәтү;

6) яшьләр инициативаларына, шул исәптән инициатив проектларына, ярдәм итү;

7) яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү;

8) яшьләрнең буш вакытын, ялын, аларны сәламәтләндерүне оештыру, яшь гражданнарны социаль һәм ил эчендәге туризмга җәлеп итү, шул исәптән походлар, экспедицияләр, слетлар, фестивальләр һәм табигый мохит шартларында уздырыла торган башка чараларны оештыру һәм үткәрү юлы белән;

9) яшьләрнең физик культура, спорт белән шөгыльләнүе өчен шартлар тудыру, сәламәт яшәү рәвешенә һәм аны яшьләр мохитендә популярлаштыруга булышлык күрсәтү, яшьләрнең социаль бурычларны физик культураны һәм спортны үстерү аша хәл итүгә юнәлдерелгән проектларына ярдәм итү;

10) яшьләргә социаль хезмәтләр күрсәтү;

11) яшьләрнең, яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтү;

12) яшь гаиләләргә ярдәм итү, яшьләр мохитендә традицион гаилә кыйммәтләрен һәм гаиләле тормыш рәвешен саклау һәм ныгыту, яшьләр арасында ата-ана җаваплылыгын тәэмин итү өчен шартлар булдыру;

13) яшьләрнең белем алуына, яшьләрнең фәнни, фәнни-техник эшчәнлегенә булышлык күрсәтү, яшь гражданнарның яңа белемнәр алуга, шул исәптән мөстәкыйль белем алу юлы белән, мотивациясен арттыру, яшь галимнәргә ярдәм итү;

14) яшьләрне хокукый агарту һәм аларга хокукый мәгълүмат бирү;

15) яшьләр белән эшләүче белгечләр әзерләүне оештыру;

16) сәләтле булуын күрсәткән яшьләрне ачыклау, аларга булышлык күрсәтү һәм ярдәм итү, яшь гражданнарның әдәби, сәнгати, фәнни, техник һәм башка төр иҗат ирегенә хокукларын гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

17) остазлык институтын үстерү;

18) яшьләргә хезмәт һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләр тәэмин итү, яшь гражданнарга эшкә урнашуга, шул исәптән студентлар отрядлары аша, яшь белгечләрнең һәм яшь хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенә булышлык күрсәтү;

19) яшьләрнең эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү һәм булышлык күрсәтү;

20) яшь гражданнарны авыл территорияләрен социаль-икътисадый үстерүгә һәм авылда яшәү рәвешенең уңайлылыгын арттыруга җәлеп итү аша аларга үз-үзләрен ачу өчен шартлар тудыру;

21) яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне башкаручы коммерциягә карамаган оешмалар һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм оешмалар каршындагы яшьләр үзидарә органнары эшчәнлегенә ярдәм итү;

22) яшьләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуына булышлык күрсәтү;

23) яшьләрдә экологик культура һәм экологик җаваплы караш булдыру;

24) яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара һәм регионара хезмәттәшлеккә булышлык күрсәтү;

25) яшьләрнең хокук бозуларын һәм җәмгатьчелеккә каршы гамәлләрен кисәтү;

26) яшьләрдә гражданлык тәңгәллеген ныгытуга, яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүгә юнәлдерелгән фән, сәнгать, әдәбият әсәрләрен һәм башка әсәрләрне булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, тарату эшчәнлегенә ярдәм итү;

27) яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча фәнни-аналитик тикшеренүләр үткәрү.»;

6) 8 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.»;

7) 12 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру турында мәгълүмат яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга кагылышлы рәсми статистик исәпкә алу белешмәләрен, Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглау, белешмәләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, яшьләр сәясәте учреждениеләре, шулай ук яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы башка оешмалар тарафыннан үз функцияләрен башкарганда алына торган бүтән белешмәләрне үз эченә ала.»;

8) 13 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау Татарстан Республикасында яшьләр хәле турында доклад (алга таба – доклад) әзерләү максатларында Татарстан Республикасында яшьләрнең, яшь гаиләләрнең һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең хәле, яшьләр сәясәте учреждениеләренең, «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия балалар һәм яшьләр иҗтимагый-дәүләти хәрәкәте эшчәнлеге турында, яшьләрнең мәгариф, агарту, фән, мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт өлкәсендә иҗтимагый файдалы эшчәнлектә катнашуы хакында, яшьләр мохитендә эш белән тәэмин ителеш һәм эшсезлек турында, яшьләр мохитендә милләтара (этносара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү хакында, яшьләрнең экстремистик иҗтимагый берләшмәләре формалашуга, яшьләр берләшмәләре эшчәнлегендә экстремизм,

агрессив милләтчелек идеологияләре чагылышларына юл куймау турында, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә яшьләрдә терроризм, экстремизм идеологияләрен, башка деструктив идеологияләрне кабул итә алмауны тәрбияләү хакында, шулай ук аларны пропагандалауга каршы торучанлык булдыру турында мәгълүмат җыю, аны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлектән гыйбарәт.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглау Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауның бер өлеше булып тора һәм гавами хакимият органнарының һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы башка субъектларның яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү буенча эшчәнлеге турында мәгълүмат җыю, аны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү эшчәнлегеннән гыйбарәт.»;

в) 4 өлештә «җирле үзидарә органнары,» сүзләреннән соң «яшьләр сәясәте учреждениеләре һәм» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 2023 елның 9 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Закон максатларында патриотик тәрбия дигәндә гавами хакимият органнарының һәм патриотик тәрбиянең башка субъектларының гражданнарда Ватанга карата мәхәббәт һәм хөрмәт, аңа тугрылык һәм Ватан язмышы өчен бүгенге һәм киләчәк буыннар алдында шәхси җаваплылык хисе, Ватанны саклау буенча, шулай ук тарихи хакыйкатьне саклау һәм тарихи хәтерне саклау буенча граждан бурычын һәм конституциячел бурычларны үтәүгә әзер булуны формалаштыру, гражданнарда гомумроссия граждан тәңгәллеге (шул исәптән Татарстан Республикасы үзенчәлекләре һәм тиешле территориядәге халыклар традицияләре нигезендә), Ватан тарихына хөрмәт һәм Ватан, аның гражданнары казанышлары белән горурлану хисен тәрбияләү һәм ныгыту, гражданнарның иҗтимагый әһәмияткә ия иҗади активлыгын үстерү буенча системалы һәм максатчан эшчәнлеге аңлашыла.»;

2) 3 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында «гореф-гадәтләренә» сүзләреннән соң «, җирле гореф-гадәтләргә» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) дәүләт һәм муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы субъектлар;»;

4) 6 статьяда:

а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$) Россия Федерациясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү чаралары комплексында каралган нигезләмәләрне, яшьләрнең социаль ихтыяҗларын, милли традицияләрне, Татарстан Республикасының региональ, җирле һәм этномәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү буенча региональ чаралар комплексын раслау һәм аны гамәлгә ашыруны оештыру;»;

б) 5 өлешкә:

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ пунктлар өстәргә:

«$4^1$) билгесез хәрби каберлекләрне һәм җирләнмәгән мәетләрне табу, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен ачыклау һәм аларның исемен мәңгеләштерү максатларында гамәлгә ашырыла торган эзләү эшен үткәрүгә вәкаләтле патриотик тәрбия бирү үзәкләре, хәрби-патриотик берләшмәләр (клублар), туган як тарихын өйрәнү оешмалары һәм эзләү оешмалары, иҗтимагый-дәүләти һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә булышлык күрсәтү;

$4^2$) яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә булышлык күрсәтү;»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглау;».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 19-ТРЗ